Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN

УНИВЕРСИТЕТ

12+

№37 (50)

20 декабрь 2012 ел

## • Универ хәлләре

**14 ДЕКАБРЬ КӨННЕ** Казан университетының Актлар залында **«ЕЛ СТУДЕНТЫ – 2012» КОНКУРСЫ ҖИНҮЧЕЛӘРЕН ТӘБРИКЛӘҮ ТАНТАНАСЫ БУЛДЫ**. Жюри ике йөздән артык катнашучының унсигезен лаеклы дип тапкан. «Ел студенты – 2012» булып юрфак студенты Роберт Зиннәтуллин танылды.

• • • •

Яр Чаллы филиалында XXI гасырның сәяси дискурсындагы яңарышларга багышланган **ХАЛЫКАРА СИМПОЗИУМ ҮЗ ЭШЧӘНЛЕГЕН БАШЛАП ҖИБӘРДЕ**. Чара 14, 17, 21 декабрь көннәрендә гамәлгә ашырыла. Симпозиум эшчәнлегендә уннан артык белгеч һәм галим катнашачак. Алар арасында Кытайдан, Испаниядән, Италиядән килгән дүрт кунак та бар. Чараның беренче көнендә филология өлкәсендәге мәсьәләләргә тукталдылар. 17 декабрьдә сәяси фәннәр кафедрасы Болон университеты вәкилләре белән берлектә миграция һәм башка иҗтимагый-сәяси аспектларны тикшерде. 21 декабрь көнне Гранада университетының (Испания) инглиз һәм алман филологиясе кафедрасының өлкән укытучысы Инкарнасьон Идальго ачык лекция үткәрер, дип көтелә. Аның чыгышы «Минем премьер-министр буласым килә, яки сәяси сөйләмне төзегәндә лингвистик үзенчәлекләр» дигән темага багышланачак.

• • • •

**17 ДЕКАБРЬДӘ РЕКТОРАТНЫҢ ЧИРАТТАГЫ УТЫРЫШЫ БУЛДЫ**. Аны аппарат җитәкчесе, Административ эшләр буенча проректор Андрей Хашов алып барды. Җыелышның башында ул контроль йөкләмәләрнең үтәлеше турында мәгълүмат бирде. Шулай ук, проректор атна буена булачак вакыйгалар белән таныштырды. Икътисади һәм стратегик үсеш буенча проректор Марат Сафиуллин КФУдагы үсеш программасының барышы турында сөйләде. 2013 елга Кабул итү кампаниясенең эшчәнлеге белән КФУның Кабул итү комиссиясенең җаваплы сәркатибе Сергей Ионенко таныштырды. Шулай ук ул КФУның төбәкара фән олимпиадалары интернет-турының нәтиҗәләре турында мәгълүмат бирде. Быелгы ярышта РФның 52 төбәгеннән һәм 3 БДБ иленнән 14900 мәктәп укучысы катнашкан. Мәгариф программаларының халыкара аккредитация һәм валидация бәясе, таләпләре һәм процедурасы турында Тышкы элемтәләр департаменты директоры Андрей Крылов сөйләде. Очрашуда КФУ хезмәткәрләрен корпоратив почта белән эшләүгә күчерү турында фикер алыштылар. Икътисад һәм финанс институты директоры Шамил Вәлитов 2012 елның октябрендә килешүгә кул куелган Вроцлав университеты белән хезмәттәшлек процессы турында сөйләде. Социаль һәм тәрбия эшчәнлеге буенча проректор Ариф Межведилов 2013 елда үтәчәк Универсиаданың әзерлек эшендә катнаша торган җаваплы кураторлар һәм волонтерларны теркәү, 5 курс студентлары үткән медицина тикшерүе нәтиҗәләре хакында мәгълүмат бирде.

• • • •

Казан федераль университетында иҗтимагый белем бирү челтәре нигезендә **ЯҢА ПРОЕКТ ЭШЛИ БАШЛАДЫ**. Ул 10 фән (рус теле, математика, физика, химия, биология, география, тарих, җәмгыять белеме, әдәбият һәм информатика) буенча 200 видеодәрестән гыйбарәт. Дәресләрдә БДИга әзерлек буенча иң авыр темалар яктыртылачак.

• • • •

**19 ДЕКАБРЬ КӨННЕ** Казан федераль университетының А.М.Бутлеров ис. Химия институтында Федераль максатчан программа кысаларында ТР Хастәханә фармакологлары җәмгыяте утырышы белән берлектә, фармакологиягә багышланган **ФӘННИ СЕМИНАР БУЛДЫ**. Чараның оештыручысы – КФУның Фәнни-мәгариф фармацевтика үзәге.

Анда даруларны куллануның фармаикътисади яклары, өлкән пациентлар белән эшләү үзенчәлекләре хакында сөйләшү булды. 2012 елгы Медицина буенча Нобель премиясе нәтиҗәләре хакында да әңгәмә кордылар.

*kpfu.ru сайты материаллары файдаланылды.*



# «Таян Аллага». Гран-При Алмазга!

**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче

«Әй бәһале, әй кадерле, әй гөнаһсыз яшь бала!
Рәхмәте бик киң аның, һәрдам таян син Аллага!»
(Габдулла Тукай)

Сүземне Габдулла Тукайның нәкъ шул шигыре белән башлавым бер дә очраклы түгел. Чөнки яшьләребезне дингә, иманга тарту, иҗади рух белән яшәтү максатын күздә тотып үткәрелә торган «Таян Аллага – 2012» конкурсына 18 декабрь көнне йомгак ясалды. Иң югары бүләк - Гран-прига университетыбыз студенты Алмаз МАНСУРОВ лаек булды.

Хәтерләсәгез, бу бәйге яз айларында ТР Мөселманнарының Диния нәзарәте, ТР Милли китапханәсе, ТР Язучылар берлеге һәм ТР Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты белән берлектә игълан ителгән иде. Билгеле, яшьләр арасыннан дини кыйммәтләргә юнәлтелгән әсәрләрне барлау зур эш! Бер дә яшерен түгел: бүген дини тематикага караган әдәп-әхлак, матурлык, шәфкать турындагы әсәрләрне язуга һәркем дә алынмый. Ә яңа буын яшьләребезне моңа тарта белү үзе үк зур җиңү! Уйлап карасаң, ислам дине – зур рухи океан! Шуңа да карамастан, рухи ләззәт алу бәхетенә халкыбызның бик азы гына омтыла. Ә иҗат аркылы аны башкаларга җиткерә белү, мавыктыру көчен булдыру «Таян Аллага» бәйгесенең төп максаты.

Оештыручыларның бүләкләү тантанасын үткәререгә күп көч куйганнары кичәнең һәр өлешендә сизелеп торды: түй табынындай мул өстәлдә хәләл ризык белән сыйлану, җиңүчеләрне зурлап тәбрикләү дисеңме... Әлбәттә аларның йөзендәге дулкынлану чалымнарын күзәтеп тору һәркемнең күңелендә якты уйлар гына барлыкка китерде.

Җиңүчебез Алмаз Филология һәм сәнгать институтының татар филологиясе бүлегендә 5 нче курста укый! Аның төрле иҗади конкурсларда беренче генә җиңүе түгел.

«Беребез дә җиңәр өчен иҗат итми. Аллаһ рәхмәте белән күңелләребезгә кирәкле сүзләр иңә икән, аларны язып кую - безнең бурычыбыз! Бу җиңүем рәхәтлек кенә түгел, ә билгеле бер җаваплылык та өсти. Сине шулай лаеклы, өметле дип күргәннәр икән, хәзер иҗат итүне һич кенә дә туктатырга ярамый! Үзем өчен иҗатымда Аллаһның рәхмәте белән тагын бер баскыч үттем дип уйлыйм. Киләсе көннәрдә дә ышанычыгызны аклап, тагын да иҗат итәргә насыйп булсын иде!» – дип Алмаз тәэсирләрен безнең белән дә уртаклашты.

КФУның филология һәм сәнгать институтында белем алучы Илнар Нотфуллин Шигърият номинациясендә өченче, ә Зөһрә Вилданова прозада икенче урынга лаек булды. Тантана ахырында «Таян Аллага-2013» конкурсы игълан ителде. Димәк, иҗат итәргә яратучы яшьләр бүгеннән үк үзләренең яңа иҗат җимешләрен конкурска җибәрә ала!

Дөрестән дә, ислам динен, әдәп-әхлак кануннарын нәфис формада халыкка җиткерү – бик әһәмиятле адым. Иҗатта кына түгел, ә көндәлек тормышыбызда да һәрдаим Аллага таянып яшәсәк иде!

■ *Рәсемдә сулдан уңга: ТР Диния нәзарәтенең уку-укыту бүлеге мөдире А.Карибуллин, А.Мансуров, конкурсның жюри әгъзасы Ф.Галимуллин.* Алинә Бикмуллина фотосы

## • Үзгәрешләр

# Яңа җитәкче

Кичә Массакүләм коммуникация һәм социаль фәннәр институтының директоры вазыйфасына яңа кеше билгеләнде. Бу вазыйфага сәясәт фәннәре докторы, профессор Наил Мөхәррәмов алынды.

Унбер ел буе башта Казан университетының журналистика һәм социология факультеты деканы, соңрак Массакүләм коммуникацияләр һәм социаль фәннәр институты директоры Васил Гарифуллин татар журналистикасы кафедрасын җитәкләүне дәвам итәчәк. Ул үзен тулысынча татар журналистлары әзерләүгә багышларга, теория базасын баетырга планлаштыра. Аның сүзләренә караганда, татар журналистикасы тарихы ничектер аерылып калган иде. Ул бу бушлыкны тулыландырырга ниятли.

Наил Мөхәррәмов КДУ аспирантурасын тәмамлаган, Мәскәү энергетика институтының Казан филиалы профессоры. Казан энергетика университетында политология һәм хокук кафедрасы мөдире булып эшләгән. Педагогика өлкәсендә хезмәт эшчәнлеге 35 ел тәшкил итә, 193 басма эш, 27дән артык уку-методика хезмәтләре авторы.

*Мәгълүмат Татар-информнан алынды.*



● Халыкара багланышлар



# Конфуций институтына биш ел!

**Гөлсем АБДУЛЛИНА,**
хәбәрче

13 декабрь көнне КФУда Конфуций институтының 5 ел дәвамында эшләп килүе уңаеннан Кытайның Чанша Хунань педагогика университетында зур тантаналы кичә булды. Бу көнне Хунань һәм Казан университетларыннан тыш Хунань провинциясенең тышкы эшләр департаменты директоры урынбасары Лю Цифән да бар иде.

КФУны тәбрикләү сүзләре белән бәйрәм тантанасын ХПУ ректоры Лю Сянжун ачып җибәрде. Университетыбызның кытай телен һәм мәдәниятен таратуга аеруча зур өлеш керткәнлеген билгеләп үтте. КФУ базасында оештырылган Конфуций институтын алар иң отышлы проект дип тапты.

КФУның тышкы элемтәләр бүлеге проректоры, Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара багланышлар институты директоры Ленар Латыйпов үз чыгышында мондый хезмәттәшлекнең уңай нәтиҗәләргә генә китерүен әйтте: «Тарихыбызга күз салсак, Россия һәм Кытай үзара яхшы мөнәсәбәттә торган дәүләтләр. КФУ белән Хунань педагогика университетларының берләшеп эшләве исә, дуслык җепләрен тагын да ныгытып җибәрә». Л.Латыйпов шулай ук уку йортларының тәҗрибә уртаклашып киләчәктә дә бергә эшләүләренә өметләр баглавын белдерде.

Бәйрәм кысаларында Конфуций институтының 5 еллык эшчәнлегенә йомгак ясалды. Аның директоры, профессор Җәмил Зәйнуллин сүзләренә караганда, безнең регионда кытай иленең мәдәниятенә соңгы елларда игътибар аеруча нык арткан. Бу темага караган мастер-класслар, конкурслар, викторина һәм кытай лекторларының мавыктыргыч лекцияләре – моның ачык дәлиле.

Алдагы биш елга үсеш планнары төзелде, яңа максатлар куелды. Соңыннан кунаклар әлеге кичәгә багышланган фотокүргәзмәгә бардылар.

● Зур җиңү

# Алтын медаль - безнеке!

**Динара ЗИННӘТОВА,**
хәбәрче



Бу көннәрдә университетыбыз зур дәрәҗәгә ирешә – КФУның биоэкология кафедрасына Европа фән һәм сәнәгать палатасының дипломы бирелде, ә кафедра мөдире Илгизәр Ильяс улы РӘХИМОВ педагогик эшчәнлеге һәм табигать ландштафтларының антропоген трансформациясе шартларындагы фундаменталь тикшерүләре өчен алтын медаль белән бүләкләнде.

Илгизәр Рәхимов фәнни эшчәнлек белән 1986 елдан бирле шөгыльләнә. 2002 елда ул Экология белгечлеге буенча фәннәр докторы дәрәҗәсенә ирешә. 2007 елда аны Татарстанның Мәгариф һәм фән министрлыгының конфликт комиссиясе рәисе итеп билгелиләр. Быел аны Мәскәүдәге Федераль экспертлар реестрына кабул итәләр. Университетта ул – студентларның һәм хезмәттәшләренең зур хөрмәтен яулаган профессор.

Илгизәр Рәхимов шәкертләре профессор турында җылы сүзләр генә әйтә.

**Ольга:** «Ул – супер-кеше! Бик нык хөрмәт итәм. Илгизәр Ильясовичның белмәгән нәрсәсе юк! Моның өстенә әле ул бик оста җитәкче дә».

**Вероника:** «Аның лекцияләре, шаяртулары, группабыз белән чәй эчүләре, практикада кош ояларын тикшерүләр мәңгегә исемдә калачак! Бу профессорга карата хөрмәтем зур. Сәламәтлек телим сезгә, Илгизәр Ильясович!»

**Илнур:** «Укытучы буларак та, кеше буларак та Илгизәр абый соклану гына уята. Аны зур хәрефтән Кеше дип әйтер идем!»

Европаның Фән һәм сәнәгать палатасы медале югары дәрәҗәдәге хезмәт күрсәткән кешеләргә бирелә - аларның яшәгән иле, милләте, тоткан дине роль уйнамый. Төп критерий буларак лауреатның югары профессионализмы, эшчәнлегенә һәм җәмгыятькә карата җаваплылыгы бәяләнә. Әлеге оешманың медале һәм дипломы Европаның иң дәрәҗәле бүләкләреннән санала.

● Сәяхәттән кайткач

# Бөек Ефәк юлында

**Альберт БОРҺАНОВ,**
КФУның Тарих институты профессоры

Әле күптән түгел генә Төрекмәнстан якларына барып кайтырга туры килде. Язмыш җилләре янәдән бу якларга алып килде. 11-16 декабрь көннәрендә Бөек Ефәк юлын ныклап тикшерү һәм Төрекмәнстанның фәнни-тикшеренү үзәкләренең башка илләр белән хезмәттәшлекне үстерү максатыннан Халыкара фәнни конференциясендә катнаштым.

Чараны Төрекмәнстан Президенты Горбангулы Бердымөхәммәтов ярдәме белән, Төрекмәнстан Фәннәр академиясенең Тарих институты оештыра. Ашхабад шәһәрендә «Бәхетле һәм куәтле дәвердә Бөек ефәк юлының яңарышы: тирән тамырлары һәм заманча мөмкинлекләре» дип исемләнгән Халыкара фәнни форум узды.

Бөек ефәк юлы – дөнья цивилизаиясе тарихында иң мөһим казанышларның берсе. Тармакланган юллар челтәре Урта диңгездән алып, Кытайга кадәр Европа һәм Азияне кисеп үткән. Кәрваннар Амудәрья һәм Сырдәрья елгалары аша үтеп Кытай ефәкләре, Һиндстан асылташлары һәм тәмләткечләре, Иран көмешләре, Византия тукымалары, Сәмәрканд керамикасы һәм башка товарлар белән сату иткәннәр. Зур һәм бай шәһәрләр, кәсепчеләр бистәләре, кәрвансарайлар, мәчетләрнең матурлыгы ул чордагы сәүдәгәрләрне сокландыра. Бүген дә сакланган архитектура һәйкәлләре – элеккеге бөеклекнең шаһитлары.

Үзәк Азия һәм Евразия илләрендә Бөек ефәк юлын һәм аның мәдәни мирасын өйрәнүгә зур игътибар бирелә. Аңа нигезләнеп борынгы һәм урта гасыр тарихы тергезелә: этник җәмгыятьләрнең икътисады, көнкүреше, мәдәнияте һәм үсешүзгәреше, традицияләре өйрәнелә.

Бу һәйкәлләргә күп ел булса да, алар әле дә зур кызыксыну уяталар. Шул сәбәпле, бу көннәрдә узган Бөек Ефәк Юлы тарихынабагышланган конференция яңа фәнни мәгълүматларны билгеләргә, аларны төгәлләштерүгә, гомумиләштерүгә багышланган иде.

● Очрашу

# «Могҗиза ул - үзең!»

**Алинә САДЫЙКОВА,**
хәбәрче

Хәзерге яшьләрне тәртипсез, җиңел акыллы, киләчәк турында уйламыйча бүгенге көн белән яшәүчеләр дигәнне еш ишетергә туры килә. Моның алай түгеллеген 11 декабрь көнне Корстон күңел ачу үзәгенә килүчеләр раслый ала. Ул көнне «Татарстан өчен 50 иң яхшы инновацион идея» дип исемләнгән VIII Республика конкурсында талантлы яшьләрне, җиңүчеләрне тәбрикләү тантанасы үтте. Исемлектә Казан федераль университетыннан утыздан артык егет-кыз җиңүче исеменә лаек булуы аеруча шатландыра.

Газетабызның хезмәткәрләре, Фундаменталь медицина һәм биология институтының беренче курс аспирантлары, игезәк Ринат һәм Ришат МӨХӘММӘДИЕВлар да «яшьләр инновацион проекты»нда җиңеп чыгып, «Связинвестнефтехим» ААҖ стипендиаты исеменә лаек булгач, горурлык хисләре икеләтә артты!

Ринат «Микромицет лектиннары нигезендә яңа препарат» проекты ярдәмендә медицина өлкәсенә үз өлешен кертергә тели. Ул лектинның микроблар үсүен әкренәйтә торган үзлеген ачыклый. Шуның нәтиҗәсендә микробларга каршы препарат уйлап чыгарырга ниятли. Бу иммунитетны арттыра торган дару булачак. Мондый төр препаратлар барысы да үсемлекләр нигезендә ясала икән. Ринат, үз чиратында, лектиннардан ясап булганлыкны дәлилли. Алга таба, яман шеш авыруларына каршы препарат ясарга теләгәнен җиткерде.

Ришатның эшчәнлеге авыл-хуҗалыгы өлкәсенә карый. Ул «Bipolaris микромицеты нигезендә яңа югары эффектлы комплекслы ферментлы препарат» дип исемләнгән проект белән җиңү яулый һәм алга таба да аның өстендә эшләргә ниятли. Bipolaris микромицеты гидролазлар бүлеп чыгара һәм шушы гидролазларны ферментлы препаратлар ясауда киң куллана. Алар ашкайнату процессын һәм азыкны тизрәк эшкәртергә ярдәм итә. Моның төп үзенчәлеге бу гидролазның бик актив булуы. «Әгәр эшебез килеп чыкса, Россиягә чит ил препаратларын сатып аласы булмаячак. Илебездә эшләнгән булганга аның бәясе түбәнрәк, ә сыйфаты, киресенчә, бик яхшы булачак», – дип аңлатты Ришат Мөхәммәдиев.

Егетләрнең икесенең дә проектлары җиңеп чыгу бик шатлыклы вакыйга. Шулай булырга тиеш тә, чөнки алар бу эш белән берничә ел шөгыльләнә, һәр конкурста катнашып, идеялары белән уртаклаша. Ришат Мөхәммәдиев баштан ук җиңәчәгенә ышанган: «Башкача була да алмый! Без максат куйдык һәм аңа ирештек тә. Иң беренче чиратта үз-үзеңдә ышаныч булдырырга кирәк, шул очракта гына сиңа башкалар да ышаначак. Могҗизага ышанырга кирәк, ә могҗиза ул – үзең!»

– Ришатның янымда булуы миңа иң зур терәк! Башка игезәкләр кебек үк без дә бергә булганда үз-үзебезне ышанычлырак хис итәбез. Уңышыбызның сере дә икәү булгангадыр. Шулай да, иң мөһиме - ул үзеңә ышаныч! Бөтен әйбер дә беренче тапкырдан килеп чыкмаска мөмкин. Егылгансың икән, торасың да юлыңны дәвам итәсең, – ди Ринат.

Аларның да эшләре гел уң гына бармагандыр, килеп чыкмаган, күңел төшкән чаклары да булгандыр. Әмма егетләрнең инде шундый зур уңышларга ирешүе ихтыяр көчләренең нык булуын күрсәтә. Бу көннәрдә дөнья бетүгә ничек карыйсыз дип сорагач, егетләр икесе дә бертавыштан: «Дөнья бетмәячәк. Безнең әле эшлисе эшләребез бик күп», – дип җавап кайтарды.




■ *Рәсемдә: Сулдан уңга Ринат һәм Ришат Мөхәммәдиевлар.*

● Кечкенә галим

## Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ:

# «Гармунда сыздырып бер уйныйсы килә иде!»

**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче

Профессор, күп кенә дәреслекләр авторы Хатыйп абый МИҢНЕГУЛОВ студентларның иң яраткан остазыдыр, мөгаен. Һәрвакыт ачык йөзле, тәмле телле, студентларга гел ярдәм кулы сузарга әзер торган, дәресләре белән кызыксындыра алган мөгаллимне яратмый мөмкинмени соң! Ә бүгенге сәхифәбездә без Хатыйп абыйның балачагына кайтып килербез...



«Башкалар өчен әһәмиятле булмаса да, узган юлымның һәр карышы минем өчен кадерле һәм истәлекле. Чөнки ул – гомеремнең бер өлеше, яшәешемнең бер баскычы. Балачак хатирәләремнең күпчелеге туган як белән бәйле. Дөньяга аваз биргән, кендек каным тамган, тәпи йөреп киткән җирем – кечерәк кенә Апач авылы. Ул Зәй, Әлмәт, Сарман районнары тоташкан җирдә урнашкан. Туган ягымның табигате искиткеч матур!!! Кызганыч ки, туган җирнең табигате гүзәл булса да, балачагым фәкыйрьлектә, ярым ач тормышта узды. Бу – сугыш һәм аннан соңгы авыр еллар, коточкыч салым түләүләр чоры. Кешеләр колхозда берөзлексез эшләсәләр дә, хезмәт хакы бөтенләй диярлек юк иде. Мин дә әүвәл әнкәйгә ияреп, аннан үзем генә эшләп йөргәнемне яхшы хәтерлим. Бер елны кул белән җиде гектарга якын җирдә урак урдык. Үзенә күрә бу район күләмендә бер рекорд иде. Шуңа күпме түләделәр дисез: 20 килограмм бодай.



■ Сулдан уңга: Р.Гаташ, абыйсы Миргалим һәм Х.Миңнегулов, 1963 ел. Автор фотосы

Мин җиденче сыйныфны күрше Пидәр мәктәбендә тәмамладым. Укыйсы килә, ә якын-тирәдә урта мәктәп юк. Ераграк барып Сарман, Әлмәт мәктәпләрендә торып укырга матди як мөмкинлек бирми. Шунда мин бер ел колхозда эшләдем: көтү көтәргә дә, фермада маллар карарга да туры килде. Шунысы истә калган: беренче сентябрь көнне, укырга бара алмау сәбәпле, лапаска чыгып кычкырып еладым. Миңа бары бер елдан гына сигезенче сыйныфта укуны дәвам итергә мөмкинлек туды. Үзебездән 25 чакрым ераклыктагы Иске Кәшер урта мәктәбендә укыдым. Озын юл. Ике урман чыгасы бар. Аякта үзем ясаган чабата. Җәяүләп, нигездә, берүзем йөрдем. Берничә мәртәбә бүреләргә дә очрадым. Тимәделәр, кызгандылар булса кирәк. Фатирда – кеше өендә ачлы-туклы яшәү. Күрәсең, уку дәрте көчле булгандыр. Мәҗбүр итсәләр, бәлки йөрмәгән дә булыр идем. Шунысын әйтим: ул вакытта Иске Кәшер мәктәбе зур һәм мәшһүр иде. Югары сыйныфларда берничә параллель булуын хәтерлим.

Мактанып әйтүем түгел: урта мәктәптә уку елларында чаңгыда йөрү, йөгерү, ераклыкка һәм биеклеккә сикерү буенча төрле ярышларда катнаша идем. Спорттагы аерым уңышларның төп сәбәбен мин еракка йөреп укуда күрәм. Кыш көнендә, мәсәлән, Апач белән Иске Кәшер арасын күбрәк чаңгыда узам. Хәтта аерым вакытларда көнендә әйләнеп килгән чаклар да булды (50 чакрым!). Көзге, язгы көннәрдә, аеруча урман эчендә, караңгыга калгач, гел йөгереп йөрдем. Курку да булгандыр инде.

Балачакның һәм, гомумән, гомеремнең иң якты мизгелләре «кыр ягыннан» Апачка килен булып төшкән әниебез белән бәйле. (Әткәй исә бик яшьли 34 яшендә Белоруссия фронтында һәлак булды.) Утыз яшенә инде биш бала анасы булган әнкәй безнең өчен гадәти ана гына түгел, ата да, президент та, политбюро да, прокурор да булды. Аның һәр сүзе, ым-карашы безнең өчен катгый закон иде. Гомумән, мин әнкәй сүзенә каршы килгәнемне белмим. Иң мөһиме – ул безне гаделлеккә, үз хезмәтебез белән көн күрергә, кешеләрне рәнҗетмәскә өйрәтте.

Үткәннәр турында уйлаганда, үкенечле яклар да искә төшә. Безнең як гармунчылары белән мәшһүр иде. Тальянда яки хромкада сыздырып уйный белү зур дәрәҗә, абруйлы шөгыль саналды. Минем бик өйрәнәсе, уйныйсы килә иде. Тик, ни кызганыч, гармун алырга мөмкинлек булмады. Дөрес, соңрак бераз өйрәнеп карасам да, уйнарга тырышуым шыгырдатудан артыкка узмады. Һәрнәрсәнең үз вакыты була шул!

Миннән еш кына: «Әдәбият фәненә ничек килдең?» – дип сорыйлар. Моңа җавап бирү авыр. Әмма башка фәннәрне белмәгәнгә түгел. Укуым яхшы иде. Күпчелек бигеләрем бишле булды. Аеруча математика, тарих, география фәннәрен яраттым. Әмма «кызыклы китап» белән кызыксынуым яшьтән үк көчле иде. Әдәбиятны сайлавыма һич үкенмим: үзем сайлаган һәм мине сайлаган язмыш!..».

● Безнекеләр

# Хезмәткә - дан!

**Динара ЗИННӘТОВА,**
хәбәрче

КФУ Студентлары хезмәт отрядларының күпьеллык бай тарихы бар. Элек, совет чорында, студентларны бу оешмага мәҗбүри рәвештә туплаганнар. Бүген исә хезмәт сөючән яшьләр отрядларга үз теләге белән керә. Әнә шулай элеккеге традицияләр яңарыш кичерә. Бүген КФУның Хезмәт отрядлары вәкилләре балаларны сәламәтләндерү лагерьларында өйдаман булып эшли, Ямал ярымутравында - газүткәргеч, Казанда - Универсиада объектлары төзелешендә актив катнаша.

Хезмәт отрядлары бүген КФУның студент оешмалары арасында җитәрлек дәрәҗәдә финанслана, «Ел студенты» конкурсында да катнаша. Оешманың эшчәнлеге белән якыннанрак танышу өчен, биредә эш бирүчеләр белән элемтә бүлегенең җитәкчесе вазыйфасын башкарган Руслан Нуруллинга берничә сорау бирдем.

**– Оешмагыз студентларга нинди мөмкинлекләр бирә?**

– Беренчедән, яшьләр шәхес буларак үсә: коллективта эшләргә өйрәнә, тәҗрибәсен арттыра. Икенчедән, студентлар финанс ягыннан да тәэмин ителә: алар мөстәкыйль тормыш юлына баса, эшләп алынган акчаның кадерен белә башлый.

**– Студентларны белгечлекләре буенча эшкә урнаштыру мөмкинлеге бармы?**

– Әлбәттә, без шулай эшләргә тырышабыз да, ләкин һәрвакыт барып кына чыкмый. Киләчәктә без профильле отрядлар булдырырга, ягьни студентларны белгечлекләре буенча тупларга ниятлибез. Бу эштә безгә КДЭУ студент отрядлары үрнәк. Бүген аларның энергетик хезмәт отрядлары эшләп килә.

**– Сезнең ярдәм белән эшкә урнашкан студентлар лаеклы хезмәт хакы аламы? Тәҗрибә җитмәве, яшь булулары тискәре роль уйнамыймы?**

– Эш бирүчеләр үзләре безгә мөрәҗәгать итә. Шуңа күрә, тиешле тәҗрибәсе булмаган яшьләр эшкә киләсен алар алдан ук белә, аларның уңышлы карьера төзүләре өчен яхшы шартлар тудырырга тырыша. Студентларның хезмәт хакын түбән дип әйтмәс идем – ул Казандагы уртача хезмәт хакын тәшкил итә. Тагын бер өстенлегебез – без җәй айларында гына түгел, уку вакытында да эшкә урнаштырабыз. Студентларны олы юлга чыгарып, университет тормышына да зур өлеш кертергә тырышабыз.

Чыннан да, студентларны укыганда ук эшкә тарту – аларның киләчәктә уңышларга ирешүенең ныклы нигезе.

● Көлсәң - көл, еласаң - ела

# Шәм алырга өлгердеңме?

**Алинә САДЫЙКОВА, Динара МИННЕКАЕВА,**
хәбәрчеләр

21.12.2012!!! Бу датаны күргәч, синең дә башыңа шул бер уй киләме? Дөнья бетәчәк?!.. Хәлемә керәм. Хуҗа Насретдин да балаларны: «Әнә теге очта чикләвек саталар», – дип алдаган. Барсы да шунда йөгергәч: «Әллә чынлап та саталар микән?» – дип үзе дә йөгергән, ди. Мин дә шулай булдым инде: тыштан ышанмаган кебек кылансам да, күңелнең иң ерак бер өлешендә ниндидер шик яши.

Ял көннәрендә авылга кайткан идем. Анда бөтен кеше бар көченнән дөнья бетүгә әзерләнә: үлә-бетә кибеттән шәм, ашамлыклар ала, сохарилар киптерә. Безнең авыл гына түгел, бөтен Җир шарында да шул ук хәл. Бетәсе булса, шәм белән кипкән ипи генә коткара алмас шул безне...

Борынгы майя индеецлары календаре буенча 2012 елның 21 декабрь көнне чираттагы бактунның – 5125 еллык цикл – тәмамлануы көтелә. «Кагыйдә буларак, майя риваятьләрендә һәрбер бактун дәвернең алмашынуын белдерә: кояшның үлеме һәм кешелек расасының юкка чыгуы. Вулканнар атылачак, су басулар башланачак, Җирне янгыннар чолгап алачак. Дәүләтләр җир белән тигезләнәчәк, планетабыз да бетәчәк», – бу сүзләрне 1966 елда Йельс университеты профессоры Майкл Коу китабында язып калдырган була. Шулай да күп кенә чыганаклар, майялар дөнья бетү турында бер сүз дә әйтеп калдырмаганнар, дип ышандыра. Алар бары тик бер дәвернең бетеп икенчесе башлану турында гына бәян иткәннәр. Алай гына да түгел, майяларны өйрәнеп тикшергән галимнәр чор алмашыну вакыйгасы индеецлар өчен зур бәйрәм булган, дип әйтәләр.

Бу датага бәйле язылган китаплар, төшерелгән кино, тапшыруларның саны чиктән ашкан. Кеше мондый афәттән качу өчен ни генә уйлап тапмый. Россиядә, мәсәлән, кайбер төзелеш фирмалары коттеджлардан баш тартып җир асты бункерлары төзүгә күчкән. Кайбер кешеләр махсус оештырылган курсларга йөриләр. Ә кайбер иптәшләр бу форсаттан файдаланып күп акча эшләп кала...

Планетабызның иң бай кешеләренең берсе Билл Гейтс Норвегиядә Свалбард орлыклар фонды глобаль банкын ача. Икенче төрле әйткәндә, үсемлек орлыкларының саклык банкы. Аны төзүнең төп максаты: кискен һәм глобаль климат үзгәрешләре, сугышлар булган очракта файдалы үсемлекләрнең орлыкларын саклап калу. Бүгенге көндә бункерда 268000 төр орлык бар. Белгечләр әйтүенчә, анда булдырылган шартларда орлыкларны 10000 ел дәвамында сакларга мөмкин.

Франциядә хәлләр тагын да искитмәлерәк: Бюгараш тавы янында бер кечкенә генә авыл бар икән. Бөтендөнья уфологлары дөнья бетүне монда каршыларга киңәш итә. Ахырзаман көнне монда чит планета вәкилләре килеп барлык теләүчеләрне үзләре белән алып китеп, коткарачак имеш. Исән калырга теләүчеләрнең саны бихисап, алар көн дә шул тау янына барып, чит планета вәкилләренә дога кыла, коткаруларын үтенә. Шулай булгач, дуслар, төенчекләребезне төяп, сохарилар киптереп, Франциягә китсәк тә була!

Дөнья бетүне кайберәүләр 2012 елның 21 декабрендә планеталар парады белән фәнни яктан аңлатмакчы була. Бу вакытта безнең Кояш системасындагы кайбер планеталар белән беррәттән (Сатурн, Юпитер, Марс һәм Җир) галактикабызның башка системаларындагы планеталар да бер рәткә тезеләчәк. Ә бу, үз чиратында, Җир шарының авырлык үзәген тулысынча үзгәртүгә китерәчәк дигән фараз бар.

– Планеталар парады вакытында алар кояшның бер ягыннан төзелгән очракта гына безгә зыян китерергә мөмкиннәр. Мондый очракның булганы юк һәм ул булмаячак та. Тар секторда гына, 30-40 градус, берничә планета урнашырга мөмкин. Мондый күренешне без 2011 елның маенда бер күзәттек инде. Ул вакытта берәр җир тетрәү, су басу, афәт булганын хәтерлисезме? Болар барысы да уйлап чыгарылган сүз!» – дип тынычландырды безне ТР фәннәр академиясе академигы, КФУның астрономия кафедрасы җитәкчесе, профессор Наил Сәхибуллин.

Эштән кайтып барганда минем алдан гына атлаган ике мәктәп баласының (2-3 сыйныф булгандыр инде) әңгәмәсен ишеттем. Бер малай икенчесенә әти-әнисенең ничек итеп дөнья бетүгә әзерләнгәннәрен сөйләп кайта иде. Азык-төлек, шәм белән «коралланган» гаилә афәтне Казаннан читтә, авыл җирлегендә, төгәлрәк итеп әйтсәм басуда (!!!) каршыларга җыена икән. Белмим дә инде, әмма мине бу әңгәмә елмаерга мәҗбүр итте.

Шәмнәр һәм противогазлар белән «запасланган» кешеләр дөнья бетми калса да берни югалтмаячак! Аның ише әйберләрнең дә барыбер бер кирәге чыгып куя бит!

• Әдәби Ат

# Киселгән имән

Динара **ЗИННӘТОВА**,
татар журналистикасы бүлеге студенты

КҮРШЕ УРАМДА «ДРУЖБА» ТАВЫШЫ ИШЕТЕЛӘ ИДЕ. ЗӘҢГӘР КОЙМАЛЫ ЙОРТНЫҢ КАПКАСЫННАН УРТА ЯШЬЛӘРДӘГЕ БЕР ИР-АТ ЧЫКТЫ ДА, АГАЧЛАР АУГАН ТАВЫШ КИЛГӘН ТАРАФКА КАРАДЫ.

– Сабир тагын кышка утын әзерли, – диде ул, тирән сулап.

– Нигә аңа шулкадәр утын? Болай булса, авылда бер агач та калмаячак бит! – дип, аңа кушылды капка төбенә чыгып утырган күрше кызы Зәйнәп, – Касыйм абый, нигә соң аны берсе дә ачуланып булса да карамый? Ул бит бу агачларга хуҗа түгел, аларны кисәргә дә аның хакы юк!

– Әйтеп караган бар инде дә... – диде Касыйм, авызына капкан тәмәкесен кабызып. – Башын ия дә, тик тора. Икенче көнне тагын агачлар аудара башлый...

...Көн кичкә авышып килә иде. Авылның Хатирә урамында үсеп утырган карт имән янында Минвәли бабай уйланып йөри. Элек бу урамда кешеләр яшәгән. Тик олы юлга якын җирдә юлбасарлар күп булу сәбәпле, Имәнле йорт авылы читкәрәк күчеп утырган.

Алтмыш еллар элек, әле Минвәлинең егет чагында, яраткан кызы Мәүлия белән алар көн саен шушы имән янында очраштылар. Егет белән кыз өчен вакыт сизелми үтте. Нindидер бер салкын иртәдә Минвәлигә сөйгәненең аңын югалтып, йөрәген тотып җан биргүе турында хәбәр китерделәр. Ахирәттә кавышырбыз дип, өйләнергә уйламады да Минвәли карт. Гомерен ялгыз үткәрде ул. Көн саен имән каршысына килеп, еракта калган якты миз-



гелләрне исенә төшерде. Агач кайрысындагы сырлар бүген картның битендәге җыерчыкларны хәтерләтә...

Минвәли абзый сагыш тулы күзләре белән тагын бер мәртәбә имәнгә тутырып карады да, йортына таба атлады. Юл читендә ун-унбишләп кеше җыелып тора иде. Аларның арасында Минвәли Сабирның яшьле күзләрен күреп алды. Шул яктан Касыймның ачулы тавышы ишетелде:

– Синең бу агачларны кисәргә хакың юк! Кеше малы белән баерга без сиңа ирек бирмәячәкбез!

– Әйе, агачлар – халыкныкы, матурлык өчен утырткannar аларны! – дип өндәде тагын бер ачулы хатын-кыз тавышы.

– Бик хаҗәт булса, әнә, үз бакчаңдагы алмагачларны кис!

– Нәрсә дәшмисең!

– Оятсыз!

Нәфрәт тулы караш-лар йомгагында, башын иеп, Сабир тик тора. Аның күзләрендә нindидер сагыш бар иде. Халык таралышкач, Сабир да кайдадыр югалды. Минвәли карт үз йортына кереп китте.

Төн җитте. Урамнарда утлар сүнгәч, Сабирның ишегалдында Касыйм пәйда булды. Тавыш-тынсыз гына мәче сыман атлап, йорт артында урнашкан иске келәтнең ишеген ачып җибәрде. Өстенә ишелеп төшә башлаган утын өемен күреп, ишекне кире этеп япты да, үзе чыгарган тавыштан куркып, алдын-артын карамыйча йөгерде.

Көтүдән кайтканда бөтен авыл Сабирның келәтендәге «байлык» турында белә иде инде. Төшкә таба авылга тагын бер яман хәбәр таралды –Хатирә урамы каршысындагы карт имәнне кисеп киткәннәр!

Кичкә таба бер төркем халык Сабирның ишеген шакыды. Озак басып торып та, ачучы булмагач, ишекне ватарга булдылар. Суынып киткән йорт эчендә бер җан иясе дә юк иде. Шулчак Касыйм өстәлдә бер хат табып алды: «Сез мине җансыз дип уйлыйсыздыр. Минем кайчандыр гаиләм булганын да, кызым барлыгын да белмисез шул...» – дип башлана иде ул.

Хатыны белән аерылгач, бала анасында калган. Кинәт кенә яман чир белән авырып киткән кызны Германиядә генә дәвалап булачак. Элеккеге хатыны сорамаса да, ата күңеле түзмәде! Ул бит ир кеше! Шул акча җитмәү аларның гаиләләрен җимерде дә. Утын сату гына түгел, кызының исәнлеге өчен ул әллә ниләр дә эшләргә әзер!

Авылдашлары аны дөрес аңламады. Сабир туган йортын сатып, бөтенләйгә шәһәргә киткәнен әйтеп тормады.

Ул кич авыл тынычланып калгандай булды. Таң атканда Хатирә урамындагы киселгән имән янында Минвәли бабайның үле гәүдәсе табылды. Аның күз тирәсендәге җыерчыкларында әле кибеп өлгермәгән яшь тамчылары иде.

Авыл халкы көтү куарга чыкты. Касыйм нindидер тынгысызлык хисе белән тирә-ягына каранды. Күрше авыл тирәсеннән «Дружба» тавышы ишетелә иде.

• Сәламәтлек

# Җылы киенеп йөрик!

Динара **МИННЕКАЕВА**,
хәбәрче

БЕЗНЕҢ КЫШЛАР ЕЛДАН-ЕЛ САЛКЫНАЯ, ЮЛДАГЫ БӨКЕЛӘР ДӘ ОЗЫНАЯ. ТУКТАЛЫШТА АВТОБУСЛАРНЫ ДА ОЗАКЛАП КӨТӘРГӘ ҺӘМ САЛКЫНДА ТУҢЫП ТОРЫРГА ТУРЫ КИЛӘ. МОНДЫЙ ВАКЫТТА ЧЫНЫККАН КЕШЕ ДӘ ӘССЕ ҖӘЙ ТУРЫНДА ХЫЯЛЛАНАДЫР. Ә ТУҢА ТОРГАН КЕШЕГӘ НИШЛӘРГӘ СОҢ? КЫШ БАБАЙНЫҢ «КАЧЫП КЫНА ШАЯРТУЛАРЫНА» НИЧЕК ТҮЗӘРГӘ?



Медицина белгечләре әйтүенчә, туңуның ике сәбәбе бар. Беренчедән, кан йөрешенә зыян килгән булырга мөмкин, икенчедән, тирә-юньдәге температураның бик түбән булуы.

Мондый очракта психологик халәт ярдәмгә килә икән. Психологлар урамга чыгар алдыннан курыкмаска киңәш итә. Нindидер күңелле әйбер турында уйларга кирәк. Алай гына да түгел, кышны яратырга өйрәнегез! Ул безгә күпме бәхетшатлык алып килә! Җәй көне Кыш бабай килсә, бер дә рәхәт булмас иде...

Күңелегезне ышандырсагыз, тән җылысын да саклый алырсыз. Тик шулай да кайбер киңәшләргә колак салыгыз. Ач карын – суыкның иң яраткан ризыгы. Шуңа күрә ашау мәсьәләсендә бик игътибарлы булырга кирәк. Ризыгыгыз май белән аксымга бай булырга, төрле тәмләткечләр кушып пешерелергә тиеш. Аксымнар безгә җылы бирсә, тәмләткечләр кан әйләнешен һәм аш кайнату матдәләрен яхшырта.

Сыеклыкларга килгәндә исә, һич тә исерткеч эчемлекләр белән бәйләнергә ярамый. Алар организмдагы энергияне тулысынча алып бетерә. Бары тик кайнар эчемлекләр генә эчегез!

Хәрәкәттә – бәрәкәт, дип юкка гына әйтмиләр. Салкында бу мәкальнең актуаль-легенә тагын бер кат инанабыз. Әйтик, туктальшта озак итеп килми торган автобусны көтеп торганчы, җәяү күпмедер юлны үтә торыгыз. Бер урында гына таптанып торуның әллә ни файдасы тимәс.

Тагын бер мөһим фактор: өс һәм аяк киеме. Аяк киеме тар, кысып тормасын. Бу очракта калын оекбаш кына кию саклап калмаячак. Өс киеме киң булырга тиеш, хәрәкәтләнгәндә комачауламасын. Парадокс: кием никадәр аз булса, шулкадәр җылырак. Дөрес киенә белү дә бик мөһим. Табигый тукымалардан тегелгән, калын йоннан бәйләнгән күлмәкләр киегез. Шулай ук термокиемнәр дә яхшы җылытачак.

Гомумән алганда, туңмас өчен дөрес итеп киенергә, яхшы тукланырга, гел хәрәкәттә булырга кирәк! Нinди генә салкыннар булса да, күңелләрегез җылы калсын! Кыш һәрберегезгә дә шатлык алып килсен!

• Спорт



# Беренче кубок безнеке

Рифат **СӘЛАХ**

ХОККЕЙ.

Бу көннәрдә Казан (Идел буе) федераль университеты егетләре хоккей буенча Татарстан студентлар чемпионатында җиңү яулады. Финал уенында кискен көрәштә Идел буе дәүләт физкультура академиясен отты. Өченче урында – Казан дәүләт милли тикшеренү технология университеты.

12 декабрь көнне «Зилант» комплексында үткән финал уенында төп вакыт һәм овертайм тигез исәп белән төгәлләнде. Матч беткәннән соңгы буллитларда КФУ студентлары физкультура академиясендә белем алучы көндәшләреннән көчлерәк булып чыкты. Беренче тапкыр үткәрелгән бу турнирның беренче җиңүчеләре безнекеләр булуы зур куаныч. Ни дисәң дә, беренче җиңүчеләр беркайчан да онытылмыйлар бит!

СПАРТАКИАДА.

16 декабрь көнне КФУның «УНИКС» концерт-спорт комплексында «Исән бул!» спартакиадасы кысаларында бильярд ярышы үтте. Анда Казан университетының 13 командасы үзара көч сынашты. Бернче урынны юридик факультет, икенче урында Физик тәрбия һәм спорт буенча гомумуниверситет кафедрасы, өченче урында экология һәм география институты.

23 декабрь көнне спартакиаданың соңгы төре – чаңгы ярышлары булачак.

• Шигъри башваткыч

# Баобабай

Ринат **НУРУЛЛИН**

*Борһан Бабай Баобабның*
*Ботарлый Ботакларын –*
*Белмәкче Буладыр Бугай*
*Баобабта Бал Барын.*

*Барып, Бабайга Баскыч Бир,*
*Булышу Була Балдай.*
*Бәлки Бирер Берәр Бүләк*
*Булышучыга Бабай.*

* * *

*Бал Булмый Баобабларда,*
*Башваткычлар Баллырак.*
*Бу Башваткыч Болай Була:*
*«БОРҺАН + БОТАК = БАОБАБ».*

*– Баллы Булмас Башваткычлар! –*
*Быжгакланыр Берәүләр.*
*...Башваткычтагы Билгеләр*
*Балларны Белдерәләр.*

*Башваткычны Башкачарак*
*Бәяләсәк Безнеңчә:*
*Берничә Белән Берничә*
*Бергә Була Берничә.*

*Бу Биремдәге Балларны*
*Белергә Безнең Бурыч.*
*Бабайга Булышкансың Бит,*
*Берәттән Безгә Булыш.*

(Башваткычның 8 чишелеше бар.)

**!** *Узган санда чыккан башваткычның җаваплары:*
*5275 + 6275 + 1275 = 12825;*
*5345 + 6345 + 1345 = 13035.*

*Авторның «Альпинист үрмәкүчләр» китабына Ләлә ХАФИЗОВА лаек булды. Ул ике дөрес җавапны икенче булып җибәреп лигада 8 балл алды. Алинә Ганиева бу юлы да беренче. Аңа лигада 10 балл бирелә. Җиңүчеләр арасында Дилүс Шәрифуллин (7 балл), Кадрия Шәрифуллина (5 балл) бар. Гөлназ Бариева бер дөрес җавапны гына язу сәбәпле 4 балл ала.*

*ШБ лигасы турында тулырак мәгълүматны vk.com/darelfonyn адресы буенча белергә мөмкин.*

*БОРҺАН + БОТАК = БАОБАБ тигезләмәсен чишеп, җавапларын электрон почтабызга языгыз! Тагын ике сан чыккач, конкурска нәтиҗә ясыйбыз. Һәрберегез актив катнашыгыз! Җиңүчеләрне бүләкләр көтә!*

DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Рифат Гали улы Сәлахов
Иҗат коллективы: Д.Р.Миннекаева, А.Ю.Садыйкова, З.Ф.Фәсхиева, Д.Р.Зиннәтова
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.

Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Карти» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Восстание ур., 60 й.